ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.08.2025 п.г.т.Алексеевское № 336

**«2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында**

Наркотик һәм психоактив матдәләрне законсыз тарату һәм медицинага карамаган куллану масштабы дәрәҗәсен киметү, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында профилактика эшенең нәтиҗәлелеген арттыру максатында

**карар бирәм:**

1. «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасын (Кушымта) расларга.
2. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 21.02.2022 ел № 52 «2022-2024 елларга Алексеевск муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» программасын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет
җитәкчесе** **О. Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
15.08.2025 № 336 карарына
кушымта

**«2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасы**
**Паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба-Программа) |
| Программаны төп эшләүчеләр | Алексеевск муниципаль районында наркотикларга каршы комиссия (алга таба) – НКК), Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районындагы бүлеге, «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОсы, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт туризм һәм балигъ булмаганнарны профилактикалау бүлеге, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгының Алексеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге, территориаль бүлек Роспотребнадзорның Яңа Чишмә, Спас, Чистай, Алексеевск районнарындагы идарәләре. |
| Программаның максаты | Алексеевск муниципаль районында наркотик һәм психоактив матдәләрне законсыз тарату һәм медицинага карамаган куллану масштабы дәрәҗәсенең кимүе. |
| Программаның бурычлары | 1. Наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү.<br>2. Балаларны һәм яшьләрне кызыксынулар, физик культура һәм спорт берләшмәләрендә системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү.<br>3. Халыкның наркотик, алкоголь, тәмәке куллануга тискәре мөнәсәбәте һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивация формалаштыру.<br>4. Яшүсмерләр һәм яшьләр өчен дәвалау-профилактика, социаль-психологик хезмәтләр системасын камилләштерү, шулай ук наркотик |

| | |
|---|---|
| | куллануны туктаткан затларга ярдәм итү. |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы һәм этаплары | 2025 – 2027 ел |
| Программаны финанслау | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, җирле бюджет акчалары, РФ акчалары.<br>Федераль, республика бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчалары күләме ел саен төзелә торган шартнамә һәм килешү нигезендә билгеләнәчәк. |
| Программаның заказчысы | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаны башкаручылар | Наркотикларга каршы комиссия, «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССО, Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районындагы ТР бүлеге, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнарны профилактикалау бүлеге, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге, Роспотребнадзор Идарәсенең Яңа Чишмә,Спас, Чистай, Алексеевск районнарында территориаль бүлеге, , Алексеевск муниципаль районының авыл җирлекләре, «Алексеевск аграр көллияте» ДАҺБУ. |
| Программаның үтәлешен тикшереп торуны оештыру системасы | Программаның үтәлешен гомуми тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | 1. Алексеевск муниципаль районында наркотикларны законсыз куллану масштаблары дәрәҗәсенә карата киму.<br>2. Сәламәт яшәү рәвешенә йөз тоткан балалар һәм яшьләр өлешен 15% ка арттыру.<br>3. Хәвеф-хәтәр төркемендәге яшүсмер һәм яшьләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү.<br>4. Халыкның законсыз әйләнешкә җәлеп ителү дәрәҗәсенең кимүе.<br>5. Наркоманиянең криминогенлык дәрәҗәсе кимүе. |

## I. Программаны гамәлгә ашыруның төп максат һәм бурыч, сроклары

Программаның максаты-Алексеевск муниципаль районында наркотик һәм психотроп матдәләрне законсыз куллану масштабларын киметү.

Күрсәтелгән максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

- Алексеевск муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалауның бердәм системасын булдыру;
- кадрлар әзерләү һәм тәҗрибә уртаклашу: район психологлары һәм педагоглары арасында укулар оештыру, белгечләрнең семинарларда катнашуы;
- яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивация формалаштыру;
- наркотикларга бәйле яшьләрне ачыклауны профилактикалау һәм диагностикалауның нәтиҗәлелеге;
- наркотик матдәләрне законсыз куллануны туктату буенча хокук саклау органнары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- Алексеевск муниципаль районында наркотикларга каршы профилактик эшне мәгълүмати тәэмин итү һәм методик тәэмин итү системасын үстерү.

Наркотиклар таралуга каршы тору рәвешләрен һәм ысулларын даими камилләштерү зарурлыгы аркасында, шулай ук программада озак сроклы чаралар булу-булмавын исәпкә алып, аны гамәлгә ашыру 3 елга (2025 елдан 2027 елга кадәр) исәпләнгән һәм бер этапта башкарыла.

Проблеманың үзенчәлеге Алексеевск муниципаль районында наркоситуацияне даими контрольдә тотуны таләп итә, шуңа күрә программаны гамәлгә ашыруны вакытыннан алда туктату каралмый.

## II. Программаны гамәлгә ашыру механизмы һәм аның үтәлешен тикшереп тору

Программаны гамәлгә ашыру механизмына программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле оештыру һәм хокукый чаралар, программа чараларын финанслау күләмнәре һәм гамәлгә ашыру сроклары, программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү шартлары керә.

Программаның үтәлешен гомуми тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра, ул, наркотикларга каршы комиссия белән килештереп, программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, программаны гамәлгә ашыру механизмын, башкаручылар составын төгәлләштерә һәм аларны үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә.

Чараларны финанслау аларны гамәлгә ашырган өчен әлеге программаны үтәүче җаваплы затлар аша гамәлгә ашырыла.

Наркотикларга каршы комиссия утырышларында программаны үтәү эшенең барышы һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат яңгырый.

## III. Гамәлгә ашыру куркынычлары һәм нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа эшчәнлегенең төп факторлары һәм шартлары макроикътисадый һәм социаль-сәяси вәзгыять белән билгеләнә, район үсешенең гамәлгә ашырылган

сценариеннан күренгәнчә. Программаны гамәлгә ашыруның төп куркынычларына түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

- наркотрафикны арттыру, наркоҗинаятьчелекне активлаштыру;
- законсыз әйләнештә наркотикларның яңа төрләре барлыкка килү;
- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә наркотиклар рекламасының актив керүе;
- квалификацияле кадрлар белән җитәрлек тәэмин ителмәү.

Хәвеф-хәтәр килеп чыккан очракта наркотикларның законсыз әйләнеше өлкәсендә җинаятьчелекнең үсүе ихтимал; наркотикларны медицина карамагында булмаган куллануга җәлеп ителгән затларның саны артуы; законсыз әйләнештә күп санда синтетик наркотик матдәләр барлыкка килү нәтиҗәсендә наркотик матдәләр белән кискен агулануларның саны артуы;яңадан медицина булмаган наркотиклар куллануга әйләнеп кайткан затларның дәвалану, реабилитация узучылары санын арттыру.

Куркынычның килеп чыгу ихтималын киметүгә һәм нәтиҗәләрен минимальләштерүгә юнәлдерелгән чаралар:

- җинаятьчел бергәлекләр һәм оешкан наркотөркемнәр эшчәнлеген туктату буенча оператив-эзләү чараларын үткәрү;
- наркотик чараларның яңа төрләре мониторингын алып бару һәм аларны таратуга каршы тору буенча үз вакытында карарлар эшләү;
- «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә наркотикларга каршы пропаганда үткәрү;
- наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны профилактикалау, Наркомания һәм токсикомания өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар белгечләренең квалификациясен күтәрү;
- табиб билгеләмәсеннән башка наркотик һәм психотроп матдәләр кулланучы затлар белән ведомствоара комплекслы мотивацияләү системасын үстерү.

Программа чараларын гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәсе булып наркотик матдәләрнең һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә бәйле куркынычлардан гражданнарның иминлеген тәэмин итү буенча хокук саклау эшчәнлеген камилләштерү нигезендә наркомания белән авыручыларның гомуми санын киметү тора.

Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге наркотикларны законсыз куллану масштабы, наркомания белән авыручылар саны, наркотик матдәләр һәм психотроп матдәләр куллану нәтиҗәләреннән үлем очраклары саны кимүдә, наркотикларның законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүендә, наркотиклар куллануның тискәре нәтиҗәләре турында халыкка хәбәрдар булуның артуында күренә.

## IV. Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре

1. Алексеевск муниципаль районында наркотикларны законсыз куллану масштабының чагыштырма дәрәҗәсенең кимүе.
2. Сәламәт яшәү рәвешенә йөз тоткан балалар һәм яшьләр өлешен 15% ка арттыру.

3. Хәвеф-хәтәр төркемендәге яшүсмерләргә һәм яшьләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү.

4. Халыкның законсыз әйләнешкә җәлеп ителү дәрәҗәсенең кимүе.

5. Наркоманиянең криминогенлык дәрәҗәсе кимүе.

**«2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасы**

| № т/б | Юнәлеш һәм чаралар исемлеге | 2025-2027 еллар программасын финанслау | башкару срогы | башкаручылар | көтелә торган ахыргы нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| **1. Наркоманияне һәм башка асоциаль күренешләрне профилактикалауга, шәхеснең социаль җаваплылыгын тәрбияләүгә, балаларның һәм яшьләрнең сәламәт яшәү рәвешен, шул исәптән «хәвеф төркемен» формалаштыруга юнәлдерелгән эшчәнлекне оештыру.** | | | | | |
| 1.1 | Алексеевск муниципаль районында наркотиклар белән бәйле хәлләрне тасвирлаучы белешмәләрне җыю һәм анализлау, анкета үткәрү | 0 | елсаен | НКК, БББ, МБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, СЯБ, ЭЭМБ | Алексеевск муниципаль районында наркотик хәлнең үсеш динамикасы турында тулырак мәгълүмат алу |
| 1.2 | Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен, психоактив матдәләр куллануга, тәмәке тартуга, башка асоциаль күренешләргә тискәре мөнәсәбәтне пропагандалау эшчәнлеген оештыру. | 0 | Кварталга 1 тапкыр | БББ, СЯБ, МБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, ББЭБ, ЭЭМБ | Халыкта психоактив матдәләр куллануга, тәмәке тартуга, башка асоциаль күренешләргә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру. |
| 1.3 | Алексеевск муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре арасында конкурслар, наркотикларга каршы профилактик проектлар оештыру һәм үткәрү | агымдагы финанслау | 2025-2027 еллар махсус планы буенча | БББ, МБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, СЯБ | Алексеевск муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау субъектлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **1.4** | Мәгариф учреждениеләрендә укучыларны наркотикларның законсыз әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар кылуга җәлеп итүне кисәтү буенча уртак чаралар үткәрүне дәвам итәргә | агымдагы финанслау | 2025-2027ел | БББ, ЯЭСТ һәм ББПБ, ЭЭМБ, ҮРХ | Мәгариф оешмаларында укучылар тарафыннан наркотикларның законсыз әйләнеше өлкәсендә хокук бозулардан баш тарту |
| **1.5** | ПДНда исәптә торучы балигъ булмаганнарны профилактика чараларына җәлеп итү | 0 | 2025-2027ел | БББ, ЯЭСТ һәм ББПБ, МБ, ААК | ПДНда профилактик исәптә торучы балигъ булмаганнарның барлык профилактик чараларда катнашуы |
| **1.6** | Балалар һәм яшьләрне волонтерлык эшчәнлегенә җәлеп итү чаралары | 0 | 2025-2027ел | БББ, ЯЭСТ һәм ББПБ, ААК | Балалар һәм яшьләрнең волонтерлык эшчәнлегендә катнашуы |
| **1.7** | Наркотикларга каршы дөньяга караш формалаштыру нигезе буларак, физкультура һәм спорт чаралары, шул исәптән балалар һәм яшьләр арасында үткәрү | 0 | 2025-2027ел | БББ, ЯЭСТ һәм ББПБ, ААК | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру |
| **2.Кадрлар әзерләү һәм тәҗрибә уртаклашу** | | | | | |
| **2.1** | Наркотиклаштыруны профилактикалау өлкәсендә эшләүче белгечләрнең квалификациясен күтәрү курсларын узу | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | ЯЭСТ һәм ББПБ, МБ ЭЭМБ, ҮРХ, СЯБ | Наркотиклаштыруны профилактикалау өлкәсендә эшләүче белгечләрнең һөнәри компетенциясен күтәрү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **2.2** | Халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау проблемалары буенча конференцияләр, семинарлар, «түгәрәк өстәлләр » дә катнашу һәм уздыру | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | НКК, ЯЭСТ һәм ББПБ, МБ ЭЭМБ, ҮРХ, СЯБ | Наркотикларга каршы эшне оештыру өлкәсендә уңай тәҗрибәне өйрәнү һәм тарату |
| **3. Наркотик матдәләрне кулланучыларны ачыклауны диагностикалау** | | | | | |
| **3.1** | **Махсус учреждениеләрнең матди-техник базасын ныгыту** | | | | |
| **3.1.1** | Профилактик медицина тикшерүләре уздыру өчен диагностик тестлар сатып алу | республика бюджеты, муниципаль бюджет | 2025-2027 ел | ҮРХ | Халык арасында наркотик матдәләр кулланучыларны ачыклауның нәтиҗәлелеген арттыру |
| **3.1.2** | 15 яшькә җиткән укучыларга тест үткәрү | агымдагы финанслау | махсус план буенча | БББ, ҮРХ | Яшүсмерләр арасында наркотик матдәләр кулланучыларны ачыклауның нәтиҗәлелеген арттыру |
| **4. Наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору** | | | | | |
| **4.1** | Үсемлекләрдән ясалган кыргый наркотик матдәләрне юк итү. «МАК» профилактик акциясе | агымдагы финанслау | 2025-2027 еллар 01.06 дан 30.09 га кадәр ел саен | ЭЭМБ, АҖ | Наркотикларның законсыз әйләнешен булдырмау |
| **4.2** | Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә наркотик чаралар куллануны тикшереп торуның нәтиҗәле чараларын эшләү һәм | 0 | даими | ЭЭМБ, ҮРХ | Наркотик матдәләр кулланучыларны ачыклау буенча нәтиҗәлелекне арттыру |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | гамәлгә ашыру | | | | |
| **4.3** | Наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш белән шөгыльләнүче хокук саклау органнары бүлекчәләренең матди-техник базасын ныгыту | 0 | махсус план буенча | ЭЭМБ | Хокук саклау органнары эшчәнлеген камилләштерү |
| **4.4** | Шәхси составның планлы рейдлары, район чараларында тикшерү-оператив төркемнең кизү торуы | 0 | атна саен шимбә, якшәмбе | ЭЭМБ | Психоактив матдәләрне ачыклау; халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча нәтиҗәлелекне арттыру |
| **4.5** | Ирекле халык дружинасының кизү торуы (район предприятие һәм учреждениеләре вәкилләре) | агымдагы финанслау | җомга | АМР БК, АҖ, ЭЭМБ | Халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруның нәтиҗәлелеген арттыру |
| **4.6** | Гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге иминлеге таләпләренә җавап бирми торган тәмәке катнашмалары белән сәүдә итү урыннарын ачыклау эшен оештыру | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | ЭЭМБ | Халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруның нәтиҗәлелеген арттыру |
| **5. Яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивация формалаштыру** | | | | | |
| **5.1. Балаларда һәм яшьләрдә наркоманияне профилактикалау, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чараларын үткәрүне оештыру** | | | | | |
| **5.1.1** | Мәнфәгатьләр буенча спорт секцияләре, клублар челтәрен киңәйтү эшен | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | ЯЭСТ һәм ББПБ, МБ | Балаларны һәм яшүсмерләрне эш белән тәэмин итү, аларны сәламәт яшәү рәвешенә тарту |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | оештыру | | | | |
| **5.1.2** | Район белешмәләр банкын «хәвеф-хәтәр төркемнәре»балигъ булмаганнар категориясе буенча актуальләштерү | 0 | даими | СЯБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, МБ | «Хәвеф-хәтәр төркеме» яшүсмерләренә ярдәм күрсәтү |
| **5.1.3** | Балигъ булмаганнарны каникул вакытында эшкә урнаштыруны оештыру | республика бюджеты | 2025-2027ел | СЯБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, МБ, ХЯБ | Укудан буш вакытта балаларда һәм яшүсмерләрдә эчтәлекле һәм продуктив эшчәнлекне оештыруга кызыксынуның артуы |
| **5.1.4.** | Имин булмаган һәм аз керемле гаиләләрдәге балаларны савыктыру һәм ял иттерү | агымдагы финанслау | 2025-2027ел | ЯЭСТ һәм ББПБ, МБ, СЯБ | Балаларда сәламәт яшәү рәвеше белән кызыксыну формалаштыру |
| **5.1.5** | Районның торак пунктларында кызыксынган оешмалар белән берлектә наркотикларга каршы массакүләм чаралар оештыру | агымдагы финанслау | ел саен 26 июнь-наркоманиягә һәм наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш көнендә | НКК, МБ, БББ, СЯБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, АЖ | Балаларда һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвеше урнаштыру, рухи үсеш, наркотик матдәләр куллануның социаль-медицина нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү |
| **5.1.6** | Районның наркотикларга каршы акциясе «Возьмемся за руки, друзья!» | агымдагы финанслау | махсус план буенча | НКК, МБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, БББ | Уңай хокук аңын формалаштыру, укучылар арасында хокук бозуларны кисәтү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **5.1.7** | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә тематик лекцияләр, тренинглар, конкурслар, «түгәрәк өстәлләр» оештыру | агымдагы финанслау | даими | НКК, МБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, ҮРХ, ЭЭМБ, СЯБ | Укучыларга психологик ярдәм күрсәтү, аларда сәламәт яшәү рәвешенә ихтыяҗ һәм зарарлы гадәтләргә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру |
| **5.1.8** | Рухи-әхлакый тәрбия буенча балигъ булмаганнар белән якшәмбе мәктәбе, мәдрәсә эше | бюджеттан тыш акчалар | даими | СЯБ, БББ, ЯЭСТ һәм ББПБ, православие, ислам | Балигъ булмаганнарда рухи-әхлакый сыйфатларны үстерү |
| **5.1.9** | «Подросток» ведомствоара операциясен үткәрү | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел май-сентябрь | ЭЭМБ, СЯБ, ЯЭСТ һәм ББПБ, БББ | Балаларны һәм яшьләрне иҗтимагый яшьләр оешмалары белән колачлауны арттыру |
| **5.1.10** | Өлкән яшьтәге ялгыз гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча мәктәп һәм аграр көллият укучылары арасында волонтерлык эшен оештыру | җирле бюджет | даими | ЯЭСТ һәм ББПБ, БББ, ФОРПОСТ, ААК | Укучыларны волонтерлык эшчәнлегенә җәлеп итү, яшь буында патриотик хисләр һәм өлкәннәргә карата хөрмәт үстерү |
| **5.1.11.** | Тәмәке тарту катнашмаларын куллануның кеше организмы өчен социаль-медицина нәтиҗәләре турында балалар һәм ата-аналар белән мәгълүмати агарту эше балалар белән социаль-агарту эше | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | БББ, ГБСЯКҮ, ҮРХ | Балаларда һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш формалаштыру, шәхеснең рухи үсеше |
| **5.1.1** | Балигъ булмаганнар һәм | агымдагы | 2025-2027 ел | районның | Балаларда һәм яшьләрдә сәламәт |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2. | аларның ата-аналары, шулай ук өлкәннәр соравы буенча тәмәке катнашмаларын куллану проблемасы буенча индивидуаль-психологик консультация бирү. | финанслау | | психология үзәге, ГБСЯКҮ, ҮРХ | яшәү рәвешенә омтылыш формалаштыру, шәхеснең рухи үсеше |
| 5.1.13. | Музейларга, тематик күргәзмәләргә баруны оештыру, фильм һәм спектакльләр карау | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | БББ, ЯЭСТ һәм ББПБ, МБ, кинотеатр «Кама» | Балаларда һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш формалаштыру |
| 5.1.14 | Мәгариф учреждениеләрендә укучыларны наркотикларның законсыз әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар кылуга җәлеп итүне кисәтү буенча уртак чаралар үткәрү. | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | БББ, ЯЭСТ һәм ББПБ, РБК, КДНиЗП | Балаларда һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш формалаштыру |
| 5.1.15. | Мәктәп укучыларының һәм укучы яшьләрнең ПАВ ачыклау предметына республика профилактик медицина тикшерүендә катнашуын тәэмин итү | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | ҮРХ, БББ, ЭЭМБ, ААК | Балаларда һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш формалаштыру |
| **5.2. Иҗтимагый һәм дәүләт оешмаларының профилактик программаларына һәм проектларына ярдәм итү чаралары системасын эшләү һәм гамәлгә ашыру** | | | | | |
| 5.2.1 | КТС нә эләккән имин булмаган гаиләләрдәге балаларга һәм яшүсмерләргә | агымдагы финанслау | 2025-2027 ел | ЯЭСТ һәм ББПБ, БББ, Роспотребнадзор, | Балаларга һәм яшүсмерләргә социаль - психологик ярдәм күрсәтү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | социаль патронаж һәм социаль-психологик ярдәм системаларын тәэмин итү | | | СЯБ | |
| **5.2.2.** | Наркология кабинетына керүдән читләшүче наркомания һәм алкоголизмнан интегүче затларны тикшерүне оештыру | дәүләт гарантияләре программасы кысаларында | ел буе | ҮРХ, ЭЭМБ | Наркоманнар ягыннан хокук бозуларны булдырмау |
| **5.3 Наркотикларга каршы профилактик эшне методик тәэмин итүне гамәлгә ашыру** | | | | | |
| **5.3.1.** | Мәктәпкәчә,гомуми белем бирү, башлангыч һөнәри әзерлек учреждениеләрендә белем алучы балаларның ата-аналары белән наркотикларга каршы профилактик эш программасын кертү | агымдагы финанслау | махсус план буенча | БББ | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау |
| **5.3.2.** | Наркотикларга каршы тематик фильмнар сатып алу һәм аларны карауны оештыру һәм алга таба фикер алышу | агымдагы финанслау | даими | ЯЭСТ һәм ББПБ, БББ, Кинотеатр «Кама» | Наркотик куллануның социаль-медицина нәтиҗәләре турында халыкка мәгълүмат бирү |
| **5.3.3.** | Әдәбиятның тематик күргәзмәләрен оештыру | 0 | даими | ЯЭСТ һәм ББПБ, ҮРХ, МБ | Наркотик куллануның социаль-медицина нәтиҗәләре турында халыкка мәгълүмат бирү |
| **5.3.4.** | Күрсәтмә агитация чараларын тарату | агымдагы финанслау | даими | ЯЭСТ һәм ББПБ,БББ, ҮРХ, МБ | Халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау |
| **6. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында наркотикларга каршы профилактика эшен** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **мәгълүмати тәэмин итү системасын үстерү** | | | | | |
| **6.1.** | Наркотик матдәләр, алкоголь куллануга каршы юнәлдерелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру | агымдагы финанслау | даими | ЯЭСТ һәм ББПБ,БББ Роспотребнадзор, СЯБ, Газета «Заря», «Таң» | Халыкта сәламәт яшәү рәвеше урнаштыру |
| **6.2.** | Мәгълүмат кырын сыйфатлы социаль реклама белән баету (урам щитларында) | агымдагы финанслау | даими | ЯЭСТ һәм ББПБ,БББ Роспотребнадзор, СЯБ, Газета «Заря», «Таң» | Халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау |

**Шартлы билгеләр:**
**Алексеевск муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе (НКК), Алексеевск муниципаль районының Башкарма комитеты (АМР БК), «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ (БББ), Башкарма комитетының мәдәният бүлеге (МБ), Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (ЯЭСТ һәм ББПБ), халыкны эш белән тәэмин итү үзәге (ХЭТҮ), Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге (ЭЭМБ), Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлеге(ЯЭБ ЭЭМБ), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү, социаль яклау министрлыгының Алексеевск районындагы социаль яклау бүлеге» (СЯБ), «Алексеевск аграр көллияте» ДАҺБУ (ААК), «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (ҮРХ), гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм комплекслы үзәге (ГБСЯКҮ), район инвалидлар җәмгыяте (БИО), Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты (ШҖ), Үзәк китапханәләр системасы (ҮКС), «Заря», «Таң» («Заря») район газетасы, Алексеевск муниципаль районының авыл җирлекләре(АҖ), Роспотребнадзор Идарәсенең Яңа Чишмә,Спас, Чистай, Алексеевск районнарында территориаль бүлеге (Роспотребнадзор), Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләренең Алексеевск территориаль үзәге муниципаль бюджет учреждениесе(ФОРПОСТ)**

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г. Ә. Йосыпова**